ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 ноября 2019г. № 5825

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы Федераль закон, «Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль закон, «Конкурентлыкны яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезнамә, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү тәртибе турында нигезнамәне кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комите Җитәкчесенең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыру тәртибе турында» 2007 елның 22 мартындагы 1013 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2019 елның 12 ноябрендәге
5825 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен
түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү тәртибе турында
нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү тәртибе турында нигезнамә (алга таба – Нигезнамә) Россия Федерациясе Гражданнар кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ санлы Федераль закон, «Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль закон, «Конкурентлыкны яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезнамә нигезендә эшләнде.

2. Нигезнамә муниципаль учреждениеләргә һәм муниципаль казна предприятиеләренә оператив идарә хокукында һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенүнең төп принципларын һәм бердәм тәртибен билгели. Әлеге Нигезнамә җир участоклары һәм башка табигый ресурслар, шәһәр бюджеты һәм бюджеттан тыш фонд акчалары, муниципаль кыйммәтле кәгазьләр белән бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый.

3. Түләүсез файдалануга түбәндәге муниципаль мөлкәт тапшырылырга мөмкин:

1) биналар (бүлмәләр), төзелешләр, корылмалар;

2) җиһаз;

3) транспорт чаралары;

4) файдалану процессында үзләренең табигый үзенчәлекләрен югалтмый торган башка әйберләр (кулланылмый торган әйберләр).

4. Муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру шартлары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль мөлкәтне файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү;

2) муниципаль милекне торгызу, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү яки башка шактый яхшыртуга инвестицияләр җәлеп итү;

3) шәһәрне үстерү программаларын тормышка ашыру;

4) шәһәр өчен әһәмиятле булган башка социаль-икътисадый максатлар.

5. Муниципаль мөлкәт түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин:

1) Россия Федерациясе бюджет системасының барлык дәрәҗәдәге бюджетларыннан финанслана торган оешмаларга;

2) Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектының вәкиллекле һәм башкарма хакимият органнарына, муниципаль берәмлекләргә;

3) инвалидларның иҗтимагый оешмаларына;

4) сәламәтлек саклау, физкультура һәм спорт өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерцияле булмаган оешмаларга;

5) гамәлгә кую документлары нигезендә социаль проблемаларны хәл итүгә, Россия Федерациясендә гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне, шулай ук эшчәнлекнең гамәлдәге законнарда каралган башка төрләрен гамәлгә ашыру шарты белән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга;

6) дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында законнар нигезендә үткәрелгән конкурс яки аукцион нәтиҗәләре буенча дәүләт яки муниципаль контракт төзелгән оешмаларга;

7) коммерцияле булмаган оешмалар формасында оештырылган территориаль иҗтимагый үзидарәләргә (алга таба – Ссуда алучы).

6. Муниципаль мөлкәтне ссудага бирүчеләр (алга таба – Ссуда бирүче) булып оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәткә карата – муниципаль учреждениеләр, муниципаль казна предприятиеләре, хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәткә карата – муниципаль унитар предприятиеләр тора.

7. Муниципаль мөлкәт түләүсез файдалануга билгеләнмәгән срокка да, срогы күрсәтелеп тә тапшырылырга мөмкин.

8. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләре идарәсе (алга таба – ҖММИ) Нигезнамә нигезендә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүен (алга таба – түләүсез файдалану килешүе) килешенүне, төзүне, үзгәртүне, өзүне тәэмин итә, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтеннән түләүсез файдалану килешүләренең исәбен (реестрын) алып бара.

9. Ссуда бирүче тарафыннан муниципаль мөлкәтне тапшыру һәм Ссуда алучы тарафыннан мондый мөлкәтне кабул итү кабул итү-тапшыру акты буенча башкарыла.

10. Түләүсез файдалану килешүе түбәндәге шартларны үз эченә алырга тиеш:

1) түләүсез файдалануга тапшырыла торган муниципаль мөлкәтнең составы һәм бәясе;

2) тапшырыла торган муниципаль мөлкәтнең кыскача техник характеристикасы;

3) муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану срогы, аны Ссуда алучыга тапшыру һәм Ссуда бирүчегә кире кайтару тәртибе;

4) муниципаль мөлкәтне ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү һәм тиешенчә файдалану буенча якларның бурычлары;

5) Ссуда алучының муниципаль мөлкәтне карап тоту белән бәйле коммуналь хезмәтләр һәм гомуми эксплуатация чыгымнарын Ссуда бирүчегә кайтару бурычы;

6) Ссуда алучының түләүсез файдалану килешүе шартларын тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыгы.

11. Түләүсез файдалануга тапшырылган муниципаль мөлкәттән файдалануны контрольдә тотуны Башкарма комитет йөзендә Ссуда бирүче һәм муниципаль мөлкәт хуҗасы гамәлгә ашыра.

12. Муниципаль мөлкәт түләүсез файдалануга, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мондый килешүне төзү хокукына конкурслар яки аукционнар (алга таба – сатулар) нәтиҗәләре буенча бирелә.

13. Башкарма комитет карары сатулар үткәрү яисә муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга тапшыру өчен нигез булып тора.

14. Сатуларны оештыручы булып Ссуда бирүче (алга таба – Сатуларны оештыручы) тора. Сатуларны оештыручы килешү нигезендә сатуларны оештыру һәм үткәрү функцияләрен тормышка ашыру өчен юридик затны җәлеп итәргә хокуклы.

15. Сатуларны оештыручы, Башкарма комитет карары чыккан вакыттан башлап ике көн эчендә, Интернет челтәрендә сатуларны үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында torgi.gov.ru сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә.

16. Түләүсез файдалану килешүен төзүгә хокукның башлангыч бәясе бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән түләүсез файдалану килешүен төзүгә хокукның башлангыч бәясен билгеләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.

17. Сатуларда түләүсез файдалану килешүен төзүгә хокукны сатудан керә торган акчаларны, сатуларны үткәрү турындагы законнарда каралган очракларда сатуларда катнашучыларның кире кайтарылмаган задатокларын исәпләү Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 2 бүлек. Оператив идарә яки хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне, сатулар үткәрмичә, түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү тәртибе

18. Сатулар үткәрмичә түләүсез файдалану килешүе төзү «Конкурентлыкны яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ санлы Федераль законда билгеләнгән очракларда гамәлгә ашырыла.

19. Муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә түләүсез файдалануга бирүне килешенү турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиесе, муниципаль учреждение җитәкчесенең гаризасы нигез булып тора.

20. Җитәкченең хуҗалык алып бару хокукында яки оператив идарә хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында мөрәҗәгате Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә җибәрелә.

21. Мөрәҗәгатьтә муниципаль мөлкәттән файдалануның максаты, аның күздә тотылган мәйданы (яки күчемле муниципаль мөлкәтнең техник характеристикалары), урнашу урыны, файдалану срогы күрсәтелергә тиеш.

22. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар теркәлә:

1) Сссуда алучының муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә мөрәҗәгате;

2) бинаның (бүлмәнең), төзелешнең, корылманың техник паспорт күчермәсе (этажлар буенча план һәм экспликация);

3) балаларга белем һәм тәрбия бирүне, аларны үстерүне, социаль яклауны һәм аларга социаль хезмәт күрсәтүне тәэмин итү өчен мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе нәтиҗәләренең Башкарма комитетның тармак идарәсе җитәкчесе тарафыннан расланган эксперт бәяләве (балалар белән эшчәнлек алып бара торган учреждениеләр өчен);

4) муниципаль автономияле учреждение күзәтчелек советының «Автономияле учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ санлы Федераль законның 11 маддәсе 1 бүлегенең 8 пункты нигезендә муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга бирү рекомендациясе турында карары (автономияле учреждениеләр өчен);

5) түләүсез файдалануга тапшырыла торган муниципаль мөлкәтнең беренчел һәм калдык кыйммәте турында белешмә;

6) Ссуда алучының гамәлгә кую документлары, Ссуда алучы вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ күчермәсе.

23. Муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында яисә муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшырудан баш тарту турында карар Башкарма комитетның ҖММИ идарәсе тарафыннан Ссуда алучының мөрәҗәгате теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә кабул ителә.

24. Муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшырудан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) Ссуда алучы Нигезнамәнең 5 пунктында күрсәтелмәгән зат булып тора;

2) Ссуда алучы тарафыннан Нигезнамәнең 22 пунктында каралган документлар бирелмәү яисә тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүматны үз эченә алган документлар бирелү;

3) муниципаль мөлкәт муниципаль ихтыяҗлар өчен файдаланылу;

4) сорала торган муниципаль мөлкәткә карата аны гамәлдәге законнар кысаларында өченче затларга тапшыру турында карар кабул ителү;

5) сорала торган муниципаль мөлкәтнең Муниципаль милек реестрында булмавы;

6) сорала торган муниципаль мөлкәт Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше законнарындагы таләпләр нигезендә капиталь ремонтланырга, реконструкцияләнергә яки сүтелергә тиеш;

7) муниципаль торак булмаган фонд объекты муниципаль милектән тартып алынырга тиеш;

8) Россия Федерациясенең монополиягә каршы законнары нигезендә муниципаль мөлкәтне сатулар үткәрмичә бирү өчен нигезләр юк.

25. Ссуда бирүче шәхсән яки аның вәкаләтле заты, Нигезнамәнең 21, 22 пунктлары нигезендә документлар теркәп, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында гариза бирә.

26. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гаризаны терки һәм гариза әлеге идарәгә кергән көнне аны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

27. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм, карап тикшерү өчен, гариза Башкарма комитет Җитәкчесенә кергән көнне аны ҖММИгә җибәрә.

28. Гариза ҖММИгә кергән вакыттан башлап унбиш календарь көн эчендә, ҖММИ йөзендә, Башкарма комитет карар чыгара яисә Нигезнамәнең 24 пунктында күрсәтелгән очракларда гариза Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән вакыттан башлап утыз календарь көн эчендә нигезле баш тарту әзерли.

29. Башкарма комитетның муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында кабул ителгән карарына нигезләнеп, ҖММИ түләүсез файдалану килешүе, муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектларын әзерли һәм әлеге проектларны карар кабул ителгән вакыттан башлап биш календарь көн эчендә, имзалау өчен Ссуда бирүчегә җибәрә.

30. Ссуда бирүче түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектлары кергән вакыттан башлап өч календарь көн эчендә түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектларын имзалый һәм әлеге проектларны имзалау өчен Ссуда алучыга җибәрә.

31. Ссуда алучы түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектлары кергән вакыттан башлап өч календарь көн эчендә түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектларын имзалый һәм әлеге проектларны имзалау өчен ҖММИгә җибәрә.

32. Түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектлары ҖММИгә кергән вакыттан башлап дүрт календарь көн эчендә түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектлары ҖММИ башлыгы тарафыннан имзалана, түләүсез файдалану килешүләрне теркәү журналында теркәлә һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль мөлкәтеннән түләүсез файдалану килешүләре реестрына кертелә.

33. Ссуда бирүче муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга кыска сроклы чорга (алдагы алты календарь ай эчендә утыз көннән дә артык түгел) килешенүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, Ссуда бирүче һәм Ссуда алучы Башкарма комитетның муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында карары теркәлгән көннән башлап ун көнлек срокта түләүсез файдалану килешүе төзиләр.

34. ҖММИ түләүсез файдалану килешүе һәм муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты проектларын имзалау өчен Ссуда бирүчегә җибәргән вакыттан башлап ун эш көне эчендә түләүсез файдалану килешүен имзалау нигезсез тоткарланган очракта, Башкарма комитет муниципаль мөлкәтне

түләүсез файдалануга тапшыруны килешенү турында кабул ителгән карарны гамәлдән чыгара.

## 3 бүлек. Оператив идарә яки хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатулар үткәрүне килешенү тәртибе

35. Муниципаль унитар предприятие, муниципаль казна предприятиясе, муниципаль учреждение җитәкчесенең оператив идарә итү яки хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатулар үткәрүне килешенү турында мөрәҗәгате Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә җибәрелә.

36. Ссуда бирүченең мөрәҗәгате Нигезнамәнең 21 пунктына туры килергә тиеш.

37. Мөрәҗәгатькә Нигезнамәнең 22 пункты 2-5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар һәм түләүсез файдалану килешүе төзү хокукының башлангыч бәясен билгеләү турында бәйсез бәяләүче тарафыннан төзелгән хисап теркәлә.

38. Сатулар нәтиҗәләре буенча муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатулар үткәрүне килешенү яисә муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыруны килешенүдән баш тарту турындагы карар, Ссуда бирүченең мөрәҗәгате теркәлгән көннән башлап 30 календарь көн эчендә ҖММИ йөзендә, Башкарма комитет тарафыннан кабул ителә.

39. Түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатуларны үткәрүдән баш тарту өчен, Нигезнамәнең 24 пунктында (1 һәм 8 пунктчалардан тыш) каралган нигезләрдән тыш, түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатулар үткәрүне килешенүдән баш тарту өчен нигез булып Ссуда бирүче тарафыннан түләүсез файдалану килешүе төзү хокукының башлангыч бәясен билгеләү турында хисап бирмәве яки әлеге хисапның бәяләү эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә туры килмәве тора.

40. Ссуда бирүче шәхсән яки аның вәкаләтле заты Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә, Нигезнамәнең 37 пункты нигезендәге документларны теркәп, муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе төзү хокукына сатулар үткәрүне килешенү турында гариза бирә.

41. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе гаризаны терки һәм гариза әлеге идарәгә кергән көнне аны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрә.

42. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм, карап тикшерү өчен, гариза Башкарма комитет Җитәкчесенә кергән көнне аны ҖММИгә җибәрә.

43. Гариза ҖММИгә кергән вакыттан башлап унбиш календарь көн эчендә, ҖММИ йөзендә, Башкарма комитет карар чыгара яисә Нигезнамәнең 39 пунктында күрсәтелгән очракларда гариза Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә кергән вакыттан башлап утыз календарь көн эчендә нигезле баш тарту әзерли һәм Башкарма комитет карары теркәлгән

көннән башлап бер эш көне эчендә әлеге карарның күчермәсен Сссуда бирүчегә җибәрә.

44. Сатуларны оештыручы, Башкарма комитет карары чыккан вакыттан башлап ике календарь көн эчендә, Интернет челтәрендә сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (torgi.gov.ru) сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә һәм сату нәтиҗәләре турында беркетмәне ҖММИгә җибәрә.

45. Сатулар нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә, ҖММИ биш календарь көн эчендә, муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектларын әзерли һәм әлеге проектларны имзалау өчен Ссуда бирүчегә җибәрә.

46. Ссуда бирүче муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектлары кергән вакыттан башлап өч календарь көн эчендә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектларын имзалый һәм әлеге проектларны имзалау өчен Ссуда алучыга җибәрә.

47. Ссуда алучы муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектлары кергән вакыттан башлап өч календарь көн эчендә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектларын имзалый һәм әлеге проектларны имзалау өчен ҖММИгә җибәрә.

48. Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектлары ҖММИгә кергән вакыттан башлап дүрт календарь көн эчендә муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүе, кабул итү-тапшыру акты проектлары ҖММИ башлыгы тарафыннан имзалана һәм ул Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүләре реестрына кертелә.

## 4 бүлек. Ссуда бирүченең һәм ссуда алучының хокуклары һәм бурычлары

49. Ссуда бирүченең хокуклары:

1) муниципаль мөлкәттән максатчан билгеләнештә һәм милекче мәнфәгатьләренә туры китереп тиешенчә файдалану һәм саклауны контрольдә тоту;

2) муниципаль мөлкәт белән идарә итү белән бәйле башка хокукларны гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашыру.

50. Ссуда алучының хокуклары:

1) ссуда бирүченең ризалыгы белән муниципаль мөлкәтнең аерылмый торган яхшыртулар бәясен түләмичә, аерылмый торган яхшыртулар булдыру;

2) гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә эшләнгән һәм расланган документлар нигезендә муниципаль мөлкәткә үз хисабына капиталь ремонт, үзгәртеп планлаштыру, реконструкция һәм кабат җиһазлау үткәрү;

3) муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалану белән бәйле тәкъдимнәр кертү;

4) гамәлдәге законнар нигезендә, муниципаль мөлкәттән файдалану белән бәйле башка хокукларны тормышка ашыру.

51. Ссуда бирүченең бурычлары:

1) түләүсез файдалану килешүе имзаланган вакыттан башлап ун көн эчендә, кабул итү-тапшыру акты буенча, залогтан һәм башка чикләүләрдән азат булган муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты нигезендә аңа караган барлык кирәк-яраклары һәм документлары белән бергә аның билгеләнешенә туры килгән хәлдә Ссуда алучыга тапшыру;

2) түләүсез файдалану килешүе имзаланган вакыттан башлап ун көн эчендә Ссуда алучы белән мөлкәтне карап тотуга бәйле коммуналь хезмәтләр һәм гомуми эксплуатация чыгымнарын каплауга килешү төзү;

3) Ссуда алучы белән берлектә муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалану һәм аны тиешле хәлдә тоту өчен кирәкле шартлар тудыруда катнашу;

4) еллык бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча Ссуда алучы белән ел саен муниципаль мөлкәт составының дөреслеген тикшерү;

5) түләүсез файдалану килешүен өзгәндә, ун көнлек срокта кабул итү-тапшыру акты буенча муниципаль мөлкәтне, аның нормаль тузуын, шулай ук аннан файдалану нәтиҗәсендә барлыкка килгән аерылмый торган барлык яхшыртуларны исәпкә алып, төзек хәлдә Ссуда алучыдан кабул итү.

52. Ссуда алучының бурычлары:

1) түләүсез файдалану килешүе имзаланган вакыттан башлап ун көн эчендә, залогтан һәм башка чикләүләрдән азат булган муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты нигезендә аңа караган барлык кирәк-яраклары һәм документлары белән бергә аның билгеләнешенә туры килгән хәлдә Ссуда бирүчедән кабул итү;

2) муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүендәге шартлар нигезендә туры билгеләнештә файдалану;

3) түләүсез файдалану килешүе имзаланган вакыттан башлап ун көнлек срокта Ссуда алучы белән мөлкәтне карап тоту белән бәйле коммуналь хезмәтләр һәм гомуми эксплуатация чыгымнарын түләүгә килешү төзү;

4) муниципаль мөлкәтне тулысынча төзек һәм тиешле санитария һәм янгын куркынычсызлыгы хәлендә тоту, әлеге максатлар өчен кирәкле матди һәм финанс средстволары бүлеп бирү;

5) күчемсез милек янәшәсендәге территорияне тиешле санитария хәлендә тоту;

6) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актлары нигезендә муниципаль мөлкәттән файдалану белән бәйле чыгымнарны түләү;

7) муниципаль мөлкәтне карап тоту белән бәйле коммуналь хезмәтләр һәм гомуми эксплуатация чыгымнарын үз вакытында түләү;

8) муниципаль мөлкәтне үз хисабына агымдагы ремонтлауны үз вакытында башкару;

9) еллык бухгалтерлык хисабы мәгълүматлары буенча Ссуда бирүче белән ел саен муниципаль мөлкәт составының дөреслеген тикшерү;

10) муниципаль мөлкәттән яки аның бер өлешеннән файдаланмаганда Ссуда бирүчегә әлеге мөлкәт турында мәгълүмат җибәрү;

11) Ссуда бирүченең язма ризалыгыннан башка, нәтиҗәсе муниципаль мөлкәтне тартып алу яки нинди дә булса чикләүләр булган яки булырга мөмкин килешүләр төземәү;

12) муниципаль мөлкәт сакланышын тәэмин итү чараларын күрү;

13) Ссуда алучылар, Ссуда бирүченең вәкилләре, дәүләт янгын күзәтчелеге хезмәте һәм биналардан файдалану һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый актлар үтәлешен контрольдә тота торган башка дәүләт органнары биләмәләрендә урнашкан бүлмәләргә керүне тәэмин итү һәм табылган кимчелекләрне алар тарафыннан билгеләнгән срокларда бетерү;

14) түләүсез файдалану килешүен өзгәндә, ун көнлек срокта кабул итү-тапшыру акты буенча муниципаль мөлкәтне, аның нормаль тузуын, шулай ук аннан файдалану нәтиҗәсендә барлыкка килгән аерылмый торган барлык яхшыртуларны исәпкә алып, төзек хәлдә Ссуда бирүчегә тапшыру;

15) түләүсез файдалану килешүен үтәүгә йогынты ясарга мөмкин булган барлык хәлләр турында Ссуда бирүчегә кичекмәстән хәбәр итү.

## 5 бүлек. Муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану килешүен үзгәртү, туктату һәм өзү

53. Әгәр законда һәм килешүдә башкача каралмаган булса, түләүсез файдалану килешүен үзгәртү һәм өзү яклар килешенүе буенча берьяклы булырга мөмкин.

54. Әгәр законда һәм башка хокукый актларда башкача каралмаган булса, түләүсез файдалану килешүен үзгәртү һәм өзү турында килешенү килешү формасында ук башкарыла.

55. Түләүсез файдалану килешүе, законда һәм килешүдә билгеләнгән очракларда, Ссуда бирүче таләбе яисә Ссуда алучы таләбе буенча срогыннан алда өзелергә мөмкин.

56. Түләүсез файдалану килешүе яклар килешенүе буенча өзелгән очракта, Ссуда бирүченең гаризасы һәм Ссуда алучының гаризасы Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә җибәрелә.

57. Түләүсез файдалану килешүе билгеләнмәгән срокка төзелгән очракта, ике якның һәркайсы теләсә нинди вакытта, андый баш тартуның күздә тотылган датасы турында башка якны өч айдан да соңрак булмаган вакытта кисәтеп, килешүдән баш тартырга хокуклы.

58. Түләүсез файдалану килешүе туктатылганда яки срогыннан алда берьяклы өзелгәндә, Ссуда алучы Ссуда бирүчегә муниципаль мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты буенча кире кайтара.

## 6 бүлек. Түләүсез файдалануга тапшырылган муниципаль мөлкәтне карап тоту чыгымнарын каплау

59. Ссуда алучы тарафыннан Ссуда бирүченең тапшырылган муниципаль мөлкәтне карап тоту өчен коммуналь хезмәтләрен түләү, гомуми эксплуатация

чыгымнарын каплау Ссуда бирүче һәм Ссуда алучы арасындагы аерым килешү буенча гамәлгә ашырыла.

60. Ссуда алучы тарафыннан коммуналь хезмәтләр (су-, газ-, электр- һәм җылылык белән тәэмин итү) өчен түләү Ссуда бирүчегә андый хезмәтләрне күрсәтүче оешма бәяләре буенча түләнергә тиеш.

Ссуда бирүченең гомуми эксплуатация чыгымнары Ссуда алучы тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен түләнә торган сумманың 20 процентыннан да артмаган суммада түләнергә тиеш.

61. Исәпләү приборлары булганда Ссуда алучы коммуналь хезмәтләр өчен аларны фактта куллану буенча түли, калган очракларда – түләүсез файдалануга тапшырылган мәйданга пропорциональ рәвештә.

62. Ссуда бирүче һәм Ссуда алучы гомуми файдаланудагы мәйданнарны бергә файдаланган очракта, аларны карап тоту чыгымнары (коммуналь хезмәтләр һәм гомуми эксплуатация чыгымнары) Ссуда алучы биләгән мәйданга пропорциональ рәвештә гомуми исәп-хисапка кертелә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова